ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СТАРОКЫРЛАЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Тукая, д. 2, с.Нижние Метески,
Арский муниципальный район, 422022

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ КЫРЛАЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Тукай урамы, 2 йорт, Түбән Мәтәскә
авылы,
Арча муниципаль районы, 422022

Тел. (84366)56-2-93, факс (84366)56-2-93. E-mail: Kuper.Ars@tatar.ru

# КАРАР

**“08” ноябрь 2021ел** **№15**

**«Агачларны, куакларны кисүгә, аларның ябалдашларын формалаштыруга, утыртуга һәм күчереп утыртуга, газонны бетерүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге Башкарма комитетының 16 август 2021ел, №11 карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Иске Кырлай авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. «Агачларны, куакларны кисүгә, аларның ябалдашларын формалаштыруга, утыртуга һәм күчереп утыртуга, газонны бетерүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге Башкарма комитетының 16 август 2021 ел, №11 карары белән расланганагачларны, куакларны кисүгә, аларның ябалдашларын формалаштыруга, утыртуга һәм күчереп утыртуга, газонны бетерүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2.3.1 пунктының 2 пунктчасында «авария хәлендәге агачлар, куаклар турында бәяләмә белән» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. 2.4.1 пунктының дүртенче абзацын төшереп калдырырга;

1.3. 2.5.4. пунктын төшереп калдырырга;

1.4. 2.6.1 пунктының 4, 5, 7 пунктчаларында «Башкарма комитет» сүзен «төзелгән килешү нигезендә муниципаль район башкарма комитеты яки җирле үзидарә органы» сүзләренә алмаштырырга;

1.5. 2.6.1 пунктының 6, 11 пунктчаларында «Башкарма комитет» сүзен «төзелгән килешү нигезендә муниципаль районның җирле үзидарә органы яки Башкарма комитет» сүзләренә алмаштырырга;

1.6. 2.6.3.пунктында «Башкарма комитетның структур бүлекчәсе» сүзләрен «муниципаль районның җирле үзидарә органнары, башкарма комитет» сүзләренә алмаштырырга;

1.7. 2.8.2 пунктының 2 пунктчасында «яки гаризада күрсәтелгән яшел үсентеләрне тикшерү нәтиҗәсендә, бик кирәк булганда (авария хәлендәге агачлар), яшел үсентеләрне юк итү зарурилыгы расланмау» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.8. 2.8.2 пунктының 5 пунктчасында. «(авария-торгызу эшләре үткәрүгә яки аеруча кирәк булганда яшел үсентеләрне юк итүгә бәйле очраклардан тыш)» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.9. 2.8.4 пунктында. «2 нче кушымтада» сүзләрен «3 нче кушымтада» сүзләренә алмаштырырга;

1.10. 3.4.2 пунктының дүртенче абзацында «шулай ук авария-торгызу эшләре үткәрү өчен яшел үсентеләрне кисүгә рөхсәт сорап мөрәҗәгать иткән очракта (авария хәлендәге, агачның аву куркынычын бетерү өчен)» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.11. 3.5.2.3 пунктны төшереп калдырырга;

1.12. 3.5.5 пунктында. «;мөрәҗәгать итүченең авария-торгызу эшләрен башкарганда яисә бик кирәк булганда яшел үсентеләрне юк итү өчен муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта (авария хәлендәге, агачның аву куркынычын бетерү өчен) – ике эш көне» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.13. Регламентның 2 нче кушымтасында «авария хәлендәге агачлар кыска вакыт эчендә киселергә тиеш.» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында игълан итәргә (pravo.tatarstan.ru), шулай ук «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң (халыкка җиткерелгәннән) үз көченә керә.

Иске Кырлай авыл җирлеге башлыгы Ф.Ф.Лутфуллин